**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫН ХӘЛ ИТҮ**
**2026 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында**
**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы**
**Аксар авыл җирлегенең Иске Тәкмәк торак пунктында**

2025 елның 14 ноябре № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Аксар авыл җирлегенең Иске Тәкмәк торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Аксар авыл җирлеге Иске Тәкмәк торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2026 елда 600 (алты йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә, шул исәптән көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, I төркем инвалидларыннан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү:
- ремонт, киртәләр кору, традицион күмү урыннарын төзекләндерү (төзелеш материаллары сатып алу, төзекләндерү, зират коймаларын урнаштыру);
- урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлау (урам яктырткычын ремонтлау);
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (юлларны ремонтлау, салу, транспорт хезмәтләре күрсәтү, төзелеш материаллары сатып алу);
- янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү (янгын колонкаларын, кәүсәләрне, җиңнәрне, янгын башы сатып алу).

3. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Иске Тәкмәк торак пунктының мәгълүмат стендларында әлеге карарны игълан итәргә, Зәй муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» урнаштырырга (PRAVO.TATARSTAN.RU) 7 көн дәвамында кабул ителгән көннән.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Аксар авыл җирлеге башлыгы ______________ Ю.И.Гильманов